
ГБМБУ «112 НЧЕ МӘКТӘП»
КАЗАН ШӘҺӘРЕ АВИАТӨЗЕЛЕШ РАЙОНЫ

# 112 ЯҢАЛЫК

# Махсус чыгарылыш

«Язмыш ! Мине этидән мәхрүм иттең ,
һәм дә энидән.Сүземне ярлыландырдың.
Мин бер нәрсәне үтенеп сорыйм:ахырга кадәр
Туган телнең шатлыгын миңа калдыр!



## Халык язмышы –шагыйрь язмышы !

Сибгат Хәким 1911 нче елның 4 декабрендә хәзерге Татарстан республикасы Әтнә районы Күлле Киме авылында туган .Мәктәпне бетергәч,30 нчы еллар башында Казанга килә,педагогика институтында укый,аннан соң”Совет әдәбияты”журналы редакциясендә эшли. 1938 нче елда аның “Беренче жыр” исемендәге китабы чыга,шул ук елны аны язучылар союзына кабул итәләр. Тукай ижатында тәрбияләнгән С.Хәким үзенең ике поэмасын бөек халык шагыйренә багышлый.

Бөек Ватан сугышы башлануның беренче көнендә үк сугышка китә,Ржев,Харьков, Курск дугасында укчылар взводы командиры булган. Сугыштан соң ул үзенең ижатын туган иленә ,аларның кешеләренә , нефтьчеләренә ,Кам АЗ төзелешенә, труба салучыларга багышлый. Аны үткән сугыш һәм киләчәктәге тормыш уйландыра. Мәсәлән “Күке”, “Утлы Курск дугасында” һәм башка әсәрләрендә чагыла. С.Хәким 10 лап жыр авторы .


1960 елда “Жил исми , яфрак селкенми” дигән жыр һәм поэма жыентыгы өчен С.Хәким Г.Тукай исемендәге Татарстан Дәүләт премиясе лауреаты, ә 1970 елда Ленин турындагы циклы өчен , аңа Горький исемендәге Российянең Дәүләт премиясе лауреаты исеме бирелә.Ул – Татарстанның халык шагыйре.
1986 елның 3 нче августында үлгән
**www.ruKazan.ru**



**С.Хәким**

**(1911-1986), ТАССР ның халык шагыйре,пубицист, жыр текстларының авторы,РСФСР ның М.Горький исемендәге һәм ТАССР ның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, ТАССР ның югары советы депутаты,Бөек Ватан сугышында катнашкан шагыйрь.**

## СИБГАТ ХӘКИМГӘ 100 ЕЛ!




Быелгысы елның декабрендә Сибгат Хәкимгә, безнең мәктәп музее горурлык белән аның исемен йөртә, 100 ел тула.

Аның шигырьләре туган республикабыздан читкә чыгып, бик күп илләрдә, бик күп телләрдә яңгырыйлар.

Тыйнаклык һәм булганлык- шагыйрь характерының төп билгеләүче төшенчәләре.

Әлеге үзенчәлекләр шигъриятендә дә чагыла. Сибгат Хәким шигырьләренең үзенчәлекле гадилеге һәм халыкчанлыгы сокландыра.

Аның шигырьләренә безнең татар композиторлары тарафыннан бик күп жырлар ижат ителгән.

Мәктәп китапханәсенә кил! Сибгат Хәкимнең шигырьләр жыентыгын кулыңа ал һәм аның чишмә суыдай саф поэзиясенә чум

*Китапханә житәкчесе:*
*Голубкова Н. А.*

# Дәүләт күләмендәге музей!

**Халык язучысы: Гариф Ахунов ( истәлекләр китабыннан)**

Зурмы, кечкенәме – һәр кешегә үзенең туган төбәге, туган шәһәре, аның табигате, кешеләре, укыган мәктәбе якын була.
Безнең мәктәбебез Авиатөзелеш районында урнашкан .Мәктәбебезнең 4нче катында музей .

Минем сезгә үзебезнең мәктәптәге музеебыз турында язасым килә.

Музей - Г.Тукай премиясе лауреаты, Россиянең М.Горький исемендәге дәүләт премиясенә лаек булган шагыйрь С. Хәким исемен йөртә. Шигъриятебез күгендә якты йолдыз булып янган шагыйрьләр арасында Сибгат аганың лаеклы урын алып торуы бәхәссез.

Музей **1981 елның 12 февралендә** татар теле укытучысы **Рәкыйпова Мөршидә Шакирҗан** кызы җитәкчелегендә оештырылган .Музей ачуда Сибгат абый үзе дә катнаша. Безнең музеебыз һәвәскәр музей гына түгел, ә дәүләт дәрәҗәсенә күтәрелгән музей. Анда үз эшенә чын күңелдән бирелгән, бөтен барлыгы белән укучыларында туган илгә, туган шәһәребезгә, газиз ана телебезгә мәһаббәт тәрбияләгән укытучыларыбыз,укучыларыбыз эшли.Музейда экскурсияләр,сыйныф сәгатьләре, очрашулар үткәрелеп тора. Быел ,ягъни декабрь аенда шагыйребезнең **100 еллык** юбилеен билгеләп үтәчәкбез. Юбилейда танылган шагыйрьләр ,җырчылар булачак. Сезне хөрмәтле әти – әниләр ,укучылар ,укытучылар музеебызда көтеп калабыз!

***Насибуллина Г. Х.***



*Мәктәпнең музей җитәкчесе: Насибуллина Г. Х.*

# Әйдәгез, үзебездән башлыйк!

Сибгат Хәкимнең юбилее якынлаша. Кызганыч, бүгенге көндә Казан урамнары буйлап узганда, яшьләрнең татар язучылары һәм шагыйрьләре турында сөйләшүләрен ишетмибез. Без күбрәк биржа яңалыкларын һәм ялтыравыклы журналлар укыйбыз.

Габдулла Тукай, Муса Җәлилләрне туган көннәре якынлашканда гына искә алабыз. Хәзерге татар әдәбияте үлгәнме? Татар шагыйрьләренең иҗаты белән кызыксынучылар калмаганмы?

Безнең шәһәребезнең бизәлешенә күз салыгыз әле!

ТАССРның халык шагыйре, публицист, бик күп җырлар авторы, РСФСРның М. Горький исемендәге Дәүләт премиясе, ТАССның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, ТАССРның Югары Совет депутаты, Бөек Ватан сугышында катнашкан шагыйрь Сибгат Хәкимнең тууына 100 ел икәнлеге турында язылган берәр игълан, транспортта реклама, баннер күргәнегез бармы?

2005 нче елда “Сибгат Хәкимнең яңа көне” чыкты. Ә яшьләр аны күрде микән? Бүген без кемнәр өчен кайгырабыз, “Дом- 2” геройлары өченме?

Сибгат Хәкимне дөньякүләм әдәбиятнең классигы дип атыйлар. Хәким татар телендә генә язса да, аны планетабызның төрле почмакларында беләләр, аның әсәрләре рус, инглиз һәм башка телләргә тәрҗемә ителгән. Аның шигырьләренә җырлар язылган.

Җырчы һәм композитор Вячеслав Никодимус башкаруында “Аккош күле”н тыңлагач, миндә шагыйрьнең башка әсәрләрен дә укыйсы килү теләге туды. Үзем өчен мин безнең якташыбызның иҗаты турында сөйләүче, Хәким шигырьләренә көй язучы, аның турында фильмнар төшерүче яңа талантлы кешене ачтым.

Хәзер адым саен шәфкатьлелек, татар мәдәниятен үстерү турында сөйлиләр. Сөйлиләр, сөйлиләр...

Әйдәгез, үзебездән башлыйк!

Кулыбызга бөек татар шагыйрьләренең әсәрләрен алыйк. ( Сибгат Хәким һәрвакыт үз халкының мәдәнияте үсешен көтеп яши)

Шагыйрь турында нәрсә белүебезне сөйлик! Музеебызга дусларны һәм танышларны чакырыйк!Без, шагыйрь турында сөйләүчеләр, артканнан артсын!

Ю. Жеренкова 10 кл.

# МИНЕМ БЕРЕНЧЕ ТАТАР ТЕЛЕ ДӘРЕСЕМ

Мәктәп. Һәрбер кешенең мәктәп еллары турында үз истәлекләре бар. Хәзергесе мәктәп миңа бигрәк тә кызык, чөнки мин укыган мәктәбемә укытучы буларак кайттым. Без укыган елларда салынган традицияләрнең бүгенгесе көндә дә матур дәвам итүе мине куандыра. Бигрәк тә мәктәп музее сөендерә. Минем беренче татар теле дәресем искә төшә ( дәресләр музейда үткәрелә иде), звоноктан соң таләпчән



укытучы Ракипова Мөршидә Шакирзяновна безне шунда алып керде. Беренче экскурсияне үткәрде, һәрбер экспонатны күрсәтеп, аларның музейга эләгү тарихын сөйләде.

Ул вакытта әле без төгәл генә аңлап бетерми идек. Ләкин башка мәктәплрдән килгән укучылар һәм кунаклар өчен экскурсияләр уздырганда бик горурлана идек. Мин Мөршидә Шакирзяновнага Сибгат Хәкимне ачканы өчен, аның поэзиясе аша туган якның матурлыгын күрә белергә өйрәткәне өчен бик зур рәхмәтлемен. Эстафетаны кабул итеп алганы өчен, музей традицияләрен бүгенгесе көндә дә дәвам иткәне өчен Насибуллина Гөлйөзем Хадиулловага да бик зур рәхмәтемне белдерәм.

***Милли тәрбия эшләре буенча директор урынбасары: Серажетдинова Ләлә Шаһитовна.***
***1993 нче елгы чыгарылыш.***

# НАС ПОКА 10!

Безнең музей – әдәбият юнәлешендәге музей.Ул мәктәпнең укыту –тәрбия өлеше булып тора.Монда даими рәвештә экскурсияләр ,сыйныф сәгатьләре,шагыйрьләр,рәссамнәр,композиторлар, С.Хәкимнең дуслары һәм туганнары катнашында кичәләр оештырыла.

Бервакытны миңа бу кичәдә катнашырга туры килде һәм мин шагыйрьне якынрак белү өчен ,экскурсия үткәрүче булу теләген әйттем.Без 10 кеше,һәркайсыбызның үз темасы бар.Экскурсияләр 3 телдә алып барыла .(татар,рус,инглиз телләрендә) Безнең музейда С.Хәкимнең шәхси әйберләре бар. Аны безгә хатыны Мөршидә апа бүләк итте.Без сезне музейга чакырып калабыз!

***Ивлева Валерия 8а***





# Иң кызыклы дәрес

Безнең сыйныф “Хәтер сугыш белән башлана “ дигән темага ,тарих дәресеннән, район күләмендә үткәрелгән семинарда катнашты.Сугыш бер кешене дә битараф калдырмады,ул һәрбер гаиләгә кагылды. Без үзебезнең якыннарның Бөек Ватан сугышында катнашулары турында эзләнү эшләре алып бардык.

Музей активларыннан без,С.Хәкимнең офицерлар курсыннан соң, Курс дугасына эләгүен белдек.Батальоннан 9 кеше кала, С.Хәким рота камандиры.. Сугышның ахырына кадәр алдынгы сафта була. Сугышның соңгы көннәрен Молдавиядә тәмамлый. Күп еллар дәвалана, сугыш турында шигырьләр яза. Сугыш ничә еллар аның төшенә кереп борчый.

Бу дәрес бөтенебезгә дә ошады. 10 ел уку дәверендә иң истә калган дәресем булды..

***Халилова А. 11 кл***

## Аккош күле – вакыт һәм буын бәйләнеше .

Гаҗәп . Беркайчан да шагыйрьнең нәрсә хакында уйлануын белмәдем. С.Хәкимнең "Аккош күле" дигән шигыренә язылган В.Никодимус башкаруындагы көйне ишеттем .Ошады. Интернеттан таптым,кат-кат тыңладым. Ә бит бу безнең Киров районындагы Аккош күле турында.Без анда бик күп тапкырлар булдык .

Аккош күле Россиядә иң яхшы күлләрнең берсе.Үз вакытында монда М.Җәлил, Ә.Исхак, С.Хәким, Ә.Фәйзи Х.Туфан кунакта булганнар .

С.Хәким 1956 елда бу урын турында язган, ә җырчы һәм композитор Вячеслав Никодимус 90 нчы елларда бу шигырьгә көй язган,ә безнең буын - 20 нче гасырда аны чын күңелдән тыңлыйбыз. Бу шигырьне укыган саен укыйсы килә. Уйланганнан соң шигырь күңелгә үтеп керә. С Хәкимнең мондый шигырьләрен кечкенә шедевр дияр идем .



**«Лебяжье озеро»**

**Улетели лебеди попарно**
**С озера в далекие края.**
**Улетел бы я вослед за ними.**
**Да, пожалуй, затоскую я.**

**Я уплыл бы в летний час на лодке**
**Вечером по звездному пути,**
**Да, пожалуй, ослабеют руки,**
**Если буду я один грести**

**Не увяла б, как тростник озерный,**
**Лебедь белая, любовь моя…**
**Без нее мое померкнет счастье,**
**И удачи не увижу я.**

**Улетели лебеди попарно,**
**Но, немым свидетельством любви,**
**Уронили нам на память перья,**
**Перья лебединые свои**

**Шагыйрьгә һәм композитор Вячеслав Никодимуска бу шигыре өчен без бик зур рәхмәтлебез Шигырь безнең күңелләрдә мәңге сакланыр .**



***Силахина Ксения 11 класс***




*Татар теле һәм әдәбияты укытучысы* ***Шакирова Диләрә Габдуллаҗан кызына*** *һәм татар теле укытучысы , Сибгат Хәким исемендәге музей житәкчесе* ***Насибуллина Гөлйөзем Хадиулла кызына*** *номерны тәрҗемә итүдә ярдәм күрсәткәннәре өчен зур рәхмәтебезне белдерәбез* .
**Баш мөхәррир : Ганиева Л.В.**
**Идеясе:** Ганиева Л.В.
**Иҗади ярдәм итүчелер :** Силахина К.,Жеренкова Ю, Ивлева В., Халилова А.,Насибуллина Г.Х., Голубкова Н.А., Серазутдинова Л.Ш.
**Программма** Mcrosoft Publisher.
**Сайт** http//:tt.wikipedia.org/wiki/Сибгат Хәким, www.ruKazan.ru
**Редакциянең адресы**:
Казан, Челюскина урамы,16
**E-mail: cabinet26-112@mail.ru**